СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.10.2023 г.Лениногорск № 51

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 26 октябрендәге 86 номерлы карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затларның ышанычын югалтуга бәйле рәвештә вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 26 октябрендәге 86 номерлы карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның ышанычын югалтуга бәйле рәвештә вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның «а» пунктчасына «,федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш,» сүзләрен өстәргә;

3 пунктның «б» пунктчасында «йә белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр бирү» сүзләрен «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, алдан ук тулы булмаган белешмәләр тапшыру йә белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру» сүзләренә алмаштырырга;»;

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Лениногорск муниципаль
районы Башлыгы,
Совет рәисе

Р.Г.Хөсәенов